КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 август г.Казань № 740

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 929 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 929 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы нигезендә һәм гомеренең беренче өч елында балаларны махсус сөт продуктлары белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидияләр бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган

бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба - Министрлык) бюджет акчаларын алучы буларак җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.»;

3 пунктта:

икенче абзацка «законнар» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы – юридик зат үзгәртеп кору, бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә субсидия алучы – индивидуаль эшмәкәр индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмаган;»;

4 пунктта:

беренче абзацка «субсидия алучыга» сүзләреннән соң «(W) (сумнарда)» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен субсидия алучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча субсидияләр бирү турында гариза, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, шул исәптән түбәндәгеләр турында мәгълүматны үз эченә алган:

субсидия алучы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

субсидия алучы – юридик зат үзгәртеп кору, бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә субсидия алучы – индивидуаль эшмәкәр индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмаган;

субсидия алучы чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны дәүләт һәм территория булган, салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирүне күздә тотмаган чит ил юридик заты һәм Россия юридик заты булып тормый.;

субсидия алучы әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормый;

субсидия алучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында кичектерелгән бүтән бурычлары юк;

субсидия алучы салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләргә ия түгел;

балалар ризыгын җитештерү өчен китерелгән сөт өчен счет-фактура күчермәсе;

балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүгә товар-транспорт накладноеның күчермәсе;

аларга субсидия алучылар сөтне балалар ризыгын җитештерү өчен төяп җибәрә торган сөт эшкәртү предприятиесе – балалар ризыгын җитештерүчедән сөт сатып алу турында реестрның расланган күчермәсе (сөт төяп җибәрү турында документлар белән расланган мәгълүматлар нигезендә);

аларга субсидия алучылар сөтне балалар ризыгын җитештерү өчен төяп җибәрә торган сөт эшкәртү предприятиеләреннән сөт сатып алу турында реестрның расланган күчермәсе, (сөт җибәрү турында документлар белән расланган мәгълүматлар нигезендә);

бирелергә тиешле субсидия турында Министрлык тарафыннан расланган форма буенча белешмә исәп-хисап.

Субсидия алучы салым органының салым, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле бурычларын булмавын раслый тоган белешмәсен үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы. Әгәр күрсәтелгән документ субсидия алучы тарафыннан үз инициативасы белән тәкъдим ителмәсә, министрлык аны салым органында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Тапшырылган документларның күчермәләре субсидияләр алучылар тарафыннан раслана»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Министрлык:

«Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында субсидияләр бирү турында гаризаларны алар кергән көнне терки;

гаризаны теркәгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә:

тапшырылган документларны әлеге Тәртипнең 6 пункты нигезендә карый һәм субсидия бирү яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи .

Кирәк булганда, Министрлык субсидия алучылар белән Килешүгә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә өстәмә килешү, шул исәптән Килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве яки аларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы;

бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы.

Бюджет йөкләмәләре лимиты җитмәгән очракта, субсидияләр гаризалар бирү чираты тәртибендә бирелә.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән вакыт узгач, эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә бу хакта гариза бирүчегә хәбәрнамә җибәрә.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Килешүдә карала:

субсидия алучы тарафыннан Министрлык  билгеләгән өстәмә хисаплар бирү формасы һәм сроклары;

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыру өчен субсидия алучының ризалыгы;

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылу ачыкланган очракта Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне кире кайтару тәртибе;

субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны күчерү тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәсенең әһәмияте»;

Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле $8^1$ һәм $8^2$ пунктлар өстәргә:

«$8^1$. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып балалар ризыгын җитештерү өчен сатылган сөт күләме тора.

$8^2$. Субсидия алучы Министрлыкка субсидия алу елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшыра.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Министрлык Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче булып тора һәм субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучыларның кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына акча күчерүне гамәлгә ашыра.

Субсидияләр күчерү өчен Министрлыкка тапшырылган алынырга тиешле субсидияләр турында белешмә исәп-хисаплар нигез булып тора.»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Бирелгән субсидияләр, әлеге Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда, министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүенең вәкаләтле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә җитмәгән очракта, Министрлык тарафыннан бирелгән субсидияләр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә тиешле таләп алынган көннән 60 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.»;

12 пунктта:

беренче абзацта «законнар белән» сүзләренә кадәр «Россия Федерациясе» сүзләренен өстәргә;

әлеге Тәртипкә кушымта өстәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 август, 740 нчы карары редакциясендә )

Форма

Торышы буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап»____»
___________ 20__ ел

Субсидия алучы исеме: ____________________________
Даимилек: субсидия алу елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр бер тапкыр

| Т/с | Нәтиҗә атамасы | ОКЕИ* буенча үлчәү берәмлеге | | Хисап датасына торышына ирешелгән нәтиҗә күрсәткече |
|---|---|---|---|---|
| | | исем | код | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 6 |
| 1. | Балалар ризыгын җитештерү өчен сатылган сөт күләме | | | |

* ОКЕИ – Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы.

Субсидия алучы җитәкче ________________ ________________________________
(имза) (Ф.И.Ә.и. (соңгысы булганда))

Баш хисапчы __________________ __________ ______________________________
(вазыйфасы) (имза) (Ф.И.Ә.и. (соңгысы булганда))

М.У. (булганда)
«___» ___________ 20__ ел

_________________________________